КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 март г.Казань № 185

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче; 2018 ел, 24 август, 706 нчы; 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 31 нче; 2019 ел, 21 июнь, 506 нчы; 2019 ел, 12 июль, 569 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инспекция карамагында бу Нигезләмә белән билгеләнгән төбәк дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә Инспекция эшчәнлеген оештыру-техник, методик, мәгълүмати һәм эксперт ясау ягыннан тәэмин итү өчен дәүләт казна учреждениесе була.»;

3.4 нче пунктның тугызынчы абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләренә алыштырырга;

3.11 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин